| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2021 г.Лениногорск № 52

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
генераль планы проектын раслау турында

«Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2021 елның 25 маеннан 2021 елның 17 августына кадәр үткәрелгән ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninoqorsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «АрхградСтройКонтроль» МБ директоры О.В. Куприяновага йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы
Башлыгы,Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов